РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 30 » 11 2023 г. №1940

«Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча муниципаль хезмәтнең башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү стандартын раслау турында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 30 октябрендәге 756 номерлы Карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты

карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының «Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын тәкъдим итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын раслау турында» 2018 елның 30 октябрендәге 756 номерлы карары белән расланган муниципаль

хезмәт күрсәтү сыйфатының стандартына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Стандартның 8 бүлеге 8.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8.3. «Педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукына, әгәр «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 №273-ФЗ Федераль закон белән башкасы билгеләнмәгән булса, урта һөнәри яки югары белемле һәм квалификация белешмәлекләрендә күрсәтелгән квалификация таләпләренә һәм (яки) һөнәри стандартларга җавап бирүче затлар ия.»;

1.2. Стандартның 7 бүлеге 7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7.3. «Оешма укырга керүчене һәм (яисә) аның ата-анасын (законлы вәкилләрен) үз уставы, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирү датасы һәм теркәү номеры турындагы мәгълүматлар, гамәлгә ашырыла торган белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе бирү датасы һәм теркәү номеры турындагы мәгълүматлар, белем бирү программалары һәм мәгариф эшчәнлеген оештыруны һәм гамәлгә ашыруны регламентташтыручы башка документлар, укучыларның хокуклары һәм бурычлары белән таныштырырга тиеш»;

1.3. Стандартның 9 бүлегенең 9.4 пунктындагы 1 пунктчасын 18 абзацта түбәндәге эчтәлек өстәргә:
«- гамәлгә ашырыла торган мәгариф программалары буенча белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе булу яисә булмау турында.»;

1.4. Стандартның 9.4 пунктындагы 2 пунктчасы 3 нче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.5. Сыйфат стандартының 9.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«9.1. Муниципаль хезмәт һәм аны күрсәтүче Белем бирү оешмасы турында мәгълүматның торышы «Кулланучылар хокукларын яклау турында» һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» федераль законнар таләпләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгариф оешмасының рәсми сайтында урнаштыру һәм мәгариф оешмасы турында мәгълүматны яңарту кагыйдәләрен раслау турында» 1802 номерлы2021 елның 20 октябрендәге Карарына туры килергә тиеш;

1.6. Стандартның 9.4 пунктындагы 1 пунктчасының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«федераль дәүләт белем бирү стандартлары, федераль дәүләт таләпләре, белем бирү стандартлары һәм мөстәкыйль билгеләнгән таләпләр турында (алар булганда);»;

1.7. Стандартның 8.4 пункты 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-тормыш һәм сәламәтлек, ирек, намус һәм дәрәҗәгә каршы җинаятьләр (стационар шартларда психиатрия ярдәме күрсәтүче медицина оешмасына законсыз госпитализацияләүдән һәм яла ягудан тыш), җенси кагылгысызлыкка һәм шәхеснең җенси ирегенә (аларга карата җинаять эзәрлекләүләре реабилитацияләү нигезләре буенча туктатылган кешеләрдән тыш), гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлакка, конституцион төзелеш нигезләренә һәм дәүләт иминлегенә каршы, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 маддәсенең өченче абзацында каралган очраклардан тыш, тынычлык һәм кешелек иминлегенә, шулай ук җәмәгать иминлегенә каршы җинаятьләре өчен хөкем ителгән, хөкем карарлары булган, җинаять эзәрлекләүләренә дучар булганнар;»;

1.8. Стандартның 8.4 пунктындагы 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясындагы өченче абзацында күрсәтелмәгән, аңлы рәвештә авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен юкка чыгарылмаган яисә үтәлмәгән хөкем карарлары булган;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина